ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның сентябренә кадәр чордагы эше турында хисабы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның сентябренә кадәр чордагы эше турында хисабын, аның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген билгеләп, игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына:

2.1. Эшчәнлеге юнәлешләре буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетлары, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнары комитетлары (комиссияләре) белән хезмәттәшлек эшен дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауны контрольдә тоту өлешендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән хезмәттәшлекне арттырырга.

2.3. Контроль мәсьәләләрне карау барышында Комитет тарафыннан кабул ителә торган карарлар нәтиҗәлелеген арттырырга.

2.3. Татарстан Республикасы законнарын үз вакытында актуальләштерү максатларында аларга мониторинг үткәрүне дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2149-VI ДС